Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез! Советлар Союзы Коммунистлар партиясе эше өчен көрәшкә әзер бул!



Яшь ленинчы

1924 елның 10 октябреннан бирле чыга

Шимбә, 29 декабрь, 1979 ел.

№ 104 (3031).

Бәясе 1 тиен.

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты һәм В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының республика советы органы

Бәрәкәтең белән кил, Яңа ел!

Кадерле балалар!

Әле узган Яңа елны каршылаганда гына сез чыршы тирәсендә әйләнеп:

Кыш бабай, Кыш бабай,
Уйнарга,
Җырларга,
Биергә куш, бабай! — дип,

мине каршы алган идегез. Ерак юллар кичеп, нәкъ бер ел үтеп китүгә мин янә сезнең янга килеп җиттем.


«Без сезне көттек! Быел безгә керергә өлгермәс ахры, дип курыккан идек», — дисезме? Онытаммы соң! Әгәр мин сезне онытам икән, күпме якын дусларым ел буена бүләксез калачак лабаса. Тик мин сезгә ел буена җитәрлек никадәр олы бәйрәмнәр алып киләм. Үземнең исемем Кыш бабай булса да, матур язларны, яшел җәйләрне, алтын көзләрне сезгә бүләк итәм. Һәр ел саен мин сезгә яңадан-яңа мәктәпләр бүләк итеп калдырам. Мина бүләкләрне әзерләшергә сезнең эш сөючән әти-әниләрегез, апа-абыйларыгыз ел буе ярдәм итәләр.



Мин сезгә ел буена җитәрлек яңа җырлар, яңа әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр, яңа рәсемнәр бүләк итеп калдырам. Яраткан газетабыз, якын дустыбыз, киңәшчебез «Яшь ленинчы» аларны ел буе биреп барачак.

Мин сезгә яңа 1980 елда олы бәйрәмнәр бүләк итеп калдырам. Шуларның иң зурысы — бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу бәйрәме. Бу олы бәйрәмгә багышланган Бөтенсоюз пионерлар Маршында лаеклы сафта булуыгызны телим.

Республикабыз Татарстанның төзелүенә 60 ел тула. Бу бәйрәмне каршылаганда сез республиканың данлы үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән танышырсыз.





Фашизмны җиңүгә 35 ел тулу бәйрәме дә көтә сезне. Партиябез, хөкүмәтебезнең коралсызлану хакындагы эшлекле тәкъдимнәре безнең өчен тынычлыкның никадәр кадерле икәнен бик ачык сөйли.

Шаулый урман, гөрли болын,
Яфрак яра тал-тирәк.
Матур тормыш корыр өчен
Безгә тынычлык кирәк.

Сезнең бу җырыгыз — бөтен хезмәт халкының уртак теләге. Әйе, дөньялар имин булсын! Әти-әниләрегез сезнең укуда, эштә булган уңышларыгызны күреп сөенсен. Ә сез, үз чиратыгызда, аларның гүзәл эшләрен күреп сөенерсез.







Менә тагын бер ел артта калды. Каршыбызда башланачак өр-яңа ел тора. Сез, чыршы тирәсендә әйләнеп, быел да миңа карап җыр җырлыйсыз:

Кыш бабай, Кыш бабай,
Уйнарга,
Җырларга,
Биергә куш, бабай!
Ә мин сезгә әйтәм:
— Уйнагыз, җырлагыз,
биегез!

Үткәнебез данлыклы.
Бүгенгебез матур.
Киләчәгебез тагын да гүзәл
булыр.
Күңелле бәйрәм сезгә,
балалар!
Яңа еллар котлы булсын!

КЫШ БАБАЙ

ЯҢА ЕЛ — ЯҢА СӨЕНЕЧ!

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе,
Син тагын да матуррак
Бизәлгәнсең бу юлы.

Яңа елның күңелле җыры дәвам итте. Берсеннән-берсе кызыклырак итеп, төрле-төрле киек-җәнлекләр, әкият геройлары булып киенгән балалар Кыш бабайны куанышып каршы алдылар. Кыш бабай үзенең яраткан дусларына яңа матур теләкләр теләде, тәмледән-тәмле күчтәнәчләр өләште. Ә балалар аны узган ел өйрәнгән җырлары, шигырьләре, яңа биюләре, уеннары белән сөендерделәр. Бу Яңа ел бәйрәмендә аларны тагын бер уен көтә икән әле.

— Дусларым, — дип башлады сүзне Шәвәли. — Сез менә спортлото, артлото уеннарын беләсез, телевизордан мультлото уенын да күргәнегез бар. Ә бездә бүген яңа уен — хатлото уены.

Шәвәли сумкасын ачып җибәрде. Идән буйлап шарлар тәгәрәп китте. Ул елмаеп лото барабанын тартып чыгарды.

Шулчак Кыш бабай үзе белән алып килгән капчыкларның берсен чишә башлады.

— Кадерле балалар, монда сезгә атап язылган дистәләгән хатлар, — диде ул серле генә итеп. — Ул хатларда үзегезнең яшьтәшләрегезнең, абый-апаларыгызның киләсе ел өчен сезгә әзерләнгән бүләкләре. Ә алар үзләре әзерләгән бу бүләкләре хакында бүгенге бәйрәмебездә шушы хатлар аша сөенечле хәбәрләр җибәрәләр.

Шул арада Шәвәли шарларны барабанга тутырып та өлгерде һәм аны әйләндереп тә җибәрде.

— Беренче отыш менеке, минеке! — дип сикереп чыкты куян баласы Озын Колак.

— Кул артың җиңел булсын! — дип, шау-гөр килделәр киек-җәнлекләр, әкият геройлары.

Куян баласы Озын Колак тәгәрәп чыккан шарны идәнгә төшеп җиткәнче үк эләктереп алды да чыршы тирәли сикерә-сикерә биеп китте.

— Отыш бар! Отыш!

Кыш бабай отышка чыккан хатны капчыгыннан алып Озын Колакка сузды. Конверт тышына «уенчык» дип язылган иде. Аны Казанның уенчыклар фабрикасы директоры **РАФИК** абый **ХӘКИМОВ** салып җибәргән.

Конвертны ачып, беренче юлларны укуга Озын Колак яңадан кулларын чәбәкләп биеп китте.

— Ур-ра! Безне киләсе елда бер миллион чамасы төрледән-төрле уенчык көтә. Арада «Йомшаккай» дип, мина аталып чыгарылганы да бар икән. Аны шундый ягымлы, сөйкемле итеп фабриканың рәссам апалары Герта Тахтенен белән Наталья Кузьминова эшләгән. «Йомшаккай»ны һәркем яратыр. Ул бит әле бишпочмаклы Сыйфат билгесен дә түшенә тагып йөртә.

Киек-җәнлекләр булып киенгән балалар шатлыкларыннан бер-берсен кочакладылар. Бүре белән куян кочаклашып биеделәр. Бу мизгелдә алардан да якын дуслар юк иде кебек. Мәче белән тычкан бер-берсенә гомерлек дуслык хакында ант та бирештеләр түгел микән әле? Төлке кызлары курчак уйнаганда беркайчан да үпкәләшмәскә сүз бирештеләр.

Хатлото уены дәвам итте. Шәвәли барабанны әйләндерә торды, Кыш бабай отышка чыккан хатларны өләшә торды. Нәни Тургай кызы музыкаль отышка ия булды. Ул хатны ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор **РЕНАТ ЕНИКЕЕВ** җибәргән иде.



— Җырдан башка яшәп буламыни, кадерле дусларым! Уен кораллары барлыкка килгәнче үк камыш сабакларында, сынган агач чыраларында җил үзенең моңлы көйләрен чыгарган. Татар халкында уен кораллары тыелган чорда безнең бабайлар:

Бие, бие Гайфулла,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булганчы,
Карт алаша тай була, — дип, такмак әйтеп биегәннәр.

Мин сезгә Яңа ел бүләге итеп «Солдат булдым» дип исемләнгән җырлар бәйләме әзерләдем. Бу җырларның бөтенесе дә пластинкага язылган. Хәзер шул әсәрнең икенче кисәген эшләп бетереп киләм. Яңа елда безне яңа очрашулар көтә, дусларым.


Әй сөенделәр, әй куандылар киек-җәнлекләр, әкият геройлары «Әкиятче» дип язылган шар чыккач. Хатны да бит әле кем салып җибәргән диген? Әкият остасы **БАТУЛЛА** үзе!

Хатны уку бәхетенә Батулла язган әкият герое — тычкан углы Такыл ия булды.

«Һәр әкият, әлбәттә, матур тәмамлана. Әкият ул — еллар шикелле. Менә быелгы ел да тәмамланды. Күркәм тәгәлләнгән әкиятнең үзе түгелмени соң ул!!

Сезгә минем бер генә теләгем бар: бу ел күркәм булган кебек, киләсе елыбыз тагын да күркәмрәк булсын! Әкияткә ышаныгыз, яшь дусларым, чөнки анда һәрвакыт саф күңелле, нык ихтыярлы, үзенең халкын, илен җаны-тәне белән яратучы каһарманнар җиңеп чыга. Гаделлек тантана итә.

БАТУЛЛА абзагыз».



Ә чираттагы отыш Тукран малае Шуктуганга эләкте. Шуктуган үзенең шуклыгы белән бөтен урман илендә билгеле. Нәкъ шуны белгән кебек, аның отышына чыккан хатны Мөслим районының Татар Буләре урта һәм Татар Шураны сигезьеллык мәктәпләреннән уку алдынгылары **ФИДАНИЯ ГӘРДЕХАНОВА** белән **ВАЛЕРИК АЛЧИН** җибәргән. Фидания дә, Валерик та — учком председательләре, икесе дә Казан университетының Ленин мемориалында рәсемгә төштеләр. Фидания ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Уку алдынгысы» значогы белән бүләкләнде, ә Валерик «Орленок» пионерлагеренда булып кайтты.



Хатны укый башлагач, Тукран малае Шуктуган бер кызарды, бер агарды да укуыннан туктап калды. Ә хатны аңа Кыш бабай үзе укып бирде. Ни хәл итәсең, өлешеңә чыккан отышың.



«Тәртипле булу, яхшы уку — төп эшебез, — диелгән иде хатта, — безнең арабызда иптәшенең әйткәнен көтеп, колак сузып торучылар бетәр-



ЯҢА ЕЛ — ЯҢА БӘХЕТ!

гә тиеш. Бернәрсә дә аңламыйча дәресне ятлап тукран кебек тукылдап торучылар да булмаска тиеш».

Хатның эчтәлеген тагын да дәвам итү кирәкмидер. Үзебездә булган кимчелекләрне, әйдәгез иске елда калдырыйк та, яңа елда безгә укуыбызны гел мактап сөйли торган отышлар гына чыксын.

— Күңелеңне төшермә, — диделәр Тукран малае Шуктуганга чыршы бәйрәмендә катнашучыларның барчасы. — Дәрес әзерләмичә килеп, бүтәннәрнең сүзен тукран кебек тукылдап тору бер нәрсә әле ул. Ә син бит агачларны дәвалыйсың. Әйдә, тукылдата бир, Шуктуган!

Бу юлы тәмлетамак керпе кызы Энәкәйнең куанычы чиктән ашты. Аның «күчтәнәч» дип язылган шарына Казан суыткыч комбинаты директоры **ИЛГИЗӘР** абый **АИТОВ** хаты чыкты.

«Кадерле дуслар, яңа елда сезгә күчтәнәчкә илле өч мең тонна мороженое әзерләп чыгарачакбыз. Туйганчы сыйланырсыз!»

— Һич аңламыйм моны, — дип сүзгә кушылды хәтерсез Тавыкбикә. — Безнеңчә генә әйтсәк, күпме мороженое була соң инде ул?

— Күпме булсын, 53 миллион данә, — дип исәпләп чыгарды Шәвәли тиз генә.

Рәсемдә: Кыш бабай — Хәлим Җәлалов.

Чираттагы отыш аю баласы Мишутканы сөендерде. Ничек сөенмәскә ди? Отыш хаты да кемнән диген?! СССРның атказанган спорт мастеры, олимпиада һәм дөнья чемпионы якташыбыз **НАИЛӘ ГЫЙЛАҖЕВАДАН.**



Бу көннәрдә ул Мәскәү олимпиадасына катнашу өчен махсус әзерләнә. Аю баласы Мишутка үз отышына чыккан бу хат белән бик тә горурланды. **«Мәскәү белән Казан арасы бик тә якын,** — дип яза **Наилә,** — **хәзерге техника заманында анда барып җитү бигрәк тә тиз. Әмма инде Мәскәү Олимпиадасына барып җитү алай гына тиз дә, җиңел дә түгел. Мин үзем бу юлга моннан дүрт ел элек, Канададан, Монреаль олимпиадасыннан кайтканда ук чыккан идем инде. Әле барасы юл һаман да ерак, алда күпме күнегүләр, күпме әзерлек тора. Көннең һәр сәгатен, һәр минутын исәпләп, үз-үзеңне аямыйча барганда гына бу юлны үтеп, максатыңа барып җитәргә мөмкин».**

— Чираттагы шар кемнеке? — диде Кыш бабай.

— Минеке! — дип кычкырды Мәче улы Мыраугали.

Тик бу юлы хатлото барабаны шактый озак әйләнеп торды. Береэдән калтырый ук башлады. Әмма җәнлекләр көткән шар һаман күренмәде. «Яңа ел галәмәте бу...» — дип пышылдады саескан, гадәттәгечә күңелгә шик салып. Һәм, чыннан да, лото барабаны тагын бер калтырап куйды да, аннан сөттәй ак шар килеп чыкты. Отышка чыккан хатны алып укысалар анда: **«...5000... Владимир Никифоров... килограмм... сыер савучы»...** — дигән өзек-өзек сүзләр язылган иде.

Аптырашта калган җәнлекләр тиз арада Балык Бистәсе районының «Масловка» совхозына шалтыраттылар. Әлеге сәер хәлне хат авторы **ВЛАДИМИР НИКИФОРОВ** үзе аңлатып бирде:

— Гафу итегез, дуслар, хат ашыгып язылды. Кичке савымга ашыга идем. Мин әле киләсе елда сыер савучы егетләр тагын да артыр, дип уйлыйм, — диде аларга Владимир, канәгатьләнеп көлә-көлә. — Ул чакта сезнең хатлото отышында минем хат кына түгел, сыер савучы егетләр турында җырлар да булыр әле, дип уйлыйм... Ә хатымда мин болай дип әйтергә булган идем: «Мин, сыер савучы Владимир Никифоров, быел сезгә күчтәнәч итеп һәр сыердан бишәр мең килограмм сөт савып алдым».

Барабан тагын әйләнде. Шарны бу юлы Шәвәли үзе алды. Анда «артист» дип язылган иде.

— Яле, Кыш бабай, — диде Шәвәли. — Чыгар әле хатны!

Кыш бабай хатны укый башлады да, туктап калды.

— Ай-һай! — диде ул. — Моны мин генә аңларлык түгел икән!

Хатны Шәвәли укыды.

«Минем бу хатымны укучы[…] кенә генә булсын, үзе сака[…] сын...»

— Минем сакалым […] зур шул! — диде Кыш[…]

се дә бер-берсенә карашып торганнан соң, чыршы ботаклары астында сикергәләп йөргән Кәҗә әби оныгы Уттоякны күреп алдылар.

— Әнә ул — Уттояк! Үзе бәләкәй дә, үзе сакаллы да. Уттояк, бу отыш синеке!

Уттояк хатны укып чыкты.


«...Һәр Яңа ел саен мин бик сәер хәлгә юлыгам: чыршы бәйрәмен карарга дип балалар бакчасының ишеген ачып керүем була, миңа көрәктәй ак сакал үсеп чыга, өстемдә — ыспай тун, билемдә — кызыл билбау, кулымда — сихерле таяк, аркамда — күчтәнәч тулы капчык пәйда була. Ә балалар мине сырып алалар да:

— Кыш бабай килгән! Кыш бабай килгән! — дип кычкыралар. Мин аларга күчтәнәчләр өләшәм, бергә уйныйм-көләм, бәйрәм итәм. Бәйрәмнән соң балалар бакчасыннан чыгуым була, сакалым да, туным да, билбавым да... юкка чыга. Кечкенә гәүдәле, бәләкәй сакаллы җан иясәрен бик зиһенле була, диләр. Бу серле хәл турында ул ни әйтер икән!

Сәлам белән, җавап көтеп
Хәлим ҖӘЛӘЛОВ,
Татарстанның атказанган артисты».

— Нәрсә әйтим, — диде Уттояк.— Балаларны шулай сөендергәне өчен Хәлим абыйга мин, Тукай абый әйтмешли, «рәхмәт укыйм, сакалым селкетәм!»

Ә соңгы отышлы шар Кырлай егете Шүрәлегә чыкты. Аңа «язучы» дип язылган шар эләкте. Кыш бабай капчыгыннан газетабызда барган «Без яшибез бәхет илендә» конкурсы лауреаты, язучы **ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ** хаты килеп чыкты.



«Балалар өчен яз, диләр. Ягъни сезнең өчен була инде ул! Ярар, язармын дим. Ә үзем икенче көнне үк яңа гына төгәлләнгән көлке хикәямне тотып «Чаян»га элдерәм. Ни хәл итәсең, сез дә бит «хәзер әйләнеп керәм» дип тау шуарга чыгып китәсез дә, онытылып, караңгы төшкәнче уйнап ташлыйсыз. Мин дә шулай! Кайтып кергәндә мыштым гына кайтып керәсең. Киләсе яңа елда тәртипле булырга сүз бирәм, сезнең өчен эчләрегезне тотып көләрлек хикәяләр язарга вәгъдә бирәм.


Яңа елда «Яшь ленинчы» укучылары: «Сез безне көлдерергә әзерме!»— дисәләр,

— Һәрвакыт әзер! — дип, җавап бирергә әзер мин».

— Менә, кадерле дусларым, хатлото уенын да уйнадык, — диде Кыш бабай. — Уен-уен инде, барыбызга да отыш чыкмаса да, беребез дә отышсыз калмады. Ә иң зур отыш — ул Яңа ел бәйрәме! Әйдәгез, биибез-җырлыйбыз:







Серле, сихри гүзәллек

Кичке эңгер. Чаллы урамнары аеруча матур бүген. Төрле-төрле төсләрдә утлар яна. Кама ягыннан талгын гына искән җилдә бөтерелә-бөтерелә Яңа елның мамык карлары ява. Урамнан шаяра-көлә ике кыз килә. Менә аларның каршысына Карсылу килеп чыга. Кызлар аны шунда ук кочаклап алалар.

— Яңа ел белән, Карсылу!

— Рәхмәт, дусларым! Сезне дә шулай ук кыш бәйрәме белән котлыйм! Кая барасыз болай?

— Культура йортына.

— Бәй, мин дә шунда барам бит.

Алар килеп җиткәндә, тамаша залы шыгрым тулы иде. Әкрен генә ут сүнеп, пәрдә ачылгач, кызлар сәхнәдәге сихри дә, серле дә гүзәллекне күреп аһ иттеләр. Минуты белән аларның күңелен спектакльдәге вакыйгалар биләп алды.

Бөек рус шагыйре А. С. Пушкин әсәре — «Патшаның үлгән кызы һәм җиде баһадир турында әкият» буенча куелган спектакль һәркемнең күңеленә хуш килерлек иде шул. Залда алкышлар бик озак яңгырап торды. Үзешчән артистларны кат-кат чакырып чыгардылар. Аларга чәчәкләр бирделәр. Чаллы мәктәпләрендә укучы малайлар һәм кызлар чын артистлардан һич ким уйнамыйлар. Алар бит инде өченче ел театр студиясенә йөриләр. Монда сәнгать серләренә төшенәләр, сәләтләрен арттыралар. Бу студия «Автозаводец» Культура йорты каршында оештырылган. Аңа режиссер Николай Михайлович Мищенко җитәкчелек итә. Студия бик күп әсәрләрне сәхнәгә куйды. «Буратино мажаралары», «Өчәүгә өч шпага», «Кар королевасы», «Балыкчы һәм алтын балык турында әкият» әнә шундыйлардан.



Яшь артистларны һәркайда — мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында — көтеп алалар. Яшь һәвәскәрләр каникул буена сәхнәдә осталыкларын күрсәтәчәкләр.

Культура йортыннан чыккач Карсылу ахирәтләренә болай диде:

— Зөһрә белән Гөлчәчәккә дә әйтим әле, килеп күрсеннәр бу спектакльне.

Рәсемнәрдә: «Балыкчы һәм алтын балык турында әкият» спектакленнән бер күренеш. Чаллы сәнгать мәктәбенең балет классында дәрес бара (өстә).

Н. ТУГАНОВ фотолары.

Әхмәт **РӘШИТОВ**

ХӘМИТ «АВТОГРАФЛАРЫ»

Ничек шулай иренмидер —
Бер минут та тик тормый;
Пәке белән дә сырлый,
Кадак белән дә тырный:

Яза уңнан сулга да,
Яза өстән аска да,
Тактага да, капкага да,
Агачка да, ташка да,

«Хәмит» дигән сүз язылган
Мәктәптәге залда да,
Комбайн һәм арбага да,
Каен белән талга да.

Бертоташтан «бизәп» йөри
Коймасын һәр кешенең,
Хәтта кәҗә мөгезенә
Язып куйган исемен.

Инде әллә ничә кеше
Тотып колагын борды,
Әллә ничә җыелышта
Кызарып басып торды.

Көн артыннан көн үтә дә,
Хәмит барын оныта,
Тагын сырлый-тырный
башлый —
Әллә кулы кычыта!!

* * *

Хәмит бүген төш күрде —
Төше дә бит нинди төш!
Бу сөйләгән хәлләрдән соң
Биш мең ел үткән, имеш.

Галимнәр авыл урынын
Актарып казыйлар, ди.
Ә җир астыннан чыга, ди,
Бик серле язулар, ди.
Язулы таш, калайлар
Ничә гасыр сау торган —
Археолог абыйларны
Аптырашта калдырган.

Авыз ерып тора Хәмит —
Аңлаучы юкмы, имеш...
Серне әйтмәкче була, тик...
Тавышы чыкмый, имеш...

* * *

Тагын бер төш күрде Хәмит—
Куркынычлы бу юлы,
Шулай тик кенә торганда
Кинәт әллә ни булды.

Койма купты урыныннан,
Капкалар атлап китте,
Һәм Хәмит сыртына кәҗә
Мөгезен китереп төртте.

Әй, берзаман кузгалдылар
Ташлар, таллар, каеннар...
Һәммәсе аны куалар —
Качарга ни җаең бар..

И, куалар, куалар, ди,
Әйтерсең лә бер кәмит,
Бөтенесе кычкырыша:
«Мин — Хәмит!» тә «Мин —
Хәмит!»

Абзарга кереп качты ул —
Үзе курка, ашыга...
Инде котылыйм дигәндә
Бер такта шалт — башына.

Әй озак кудылар аны —
Тирләде-пеште Хәмит.
Һәм уянып... караваттан
Егылып төште Хәмит.

* * *

Куркынычлы шундый төшләр
Күргәләсә гаҗәпме!
Яңа елда ташлар Хәмит
Бу килешсез гадәтне.



Газетаның беренче битендә укучылар Равил Мифтахов (Зеленодольск районы, Күгәй мәктәбе), Резеда Кәримуллина (Чирмешән районы, Югары Кәминкә авылы), Шамил Сафин (Әлмәт районы, Елховой мәктәбе), Разин Хәлиуллин (Сарман районы, Күтәмәле мәктәбе) рәсемнәре файдаланылды.



◆ Вьетнамда Яңа елны каршылау кичтән үк башлана. Караңгы төшүгә паркларда, бакча, урамнарда һәр гаилә учак ягып җибәрә. Анда бәйрәм ашы пешереп, кешеләр туганнарын, дусларын сыйлыйлар.

◆ Бирмада Яңа ел бәйрәме елның иң эссе вакытына туры килә һәм бирмалыларга гына хас «су фестивале» белән билгеләп үтелә. Бу көнне һәркем кулында сулы чиләк була, юлда очраган һәр кешегә су сибәләр: министрмы, әллә дин башлыгымы, баймы яки ярлымы— су сипкәндә аерып тормыйлар. Яңа ел белән «котлаганга» кем ачулансын!

◆ Болгариядә Яңа ел алдыннан кизил таягы сатып алалар. 1 январьда шуның белән әкрен генә сугып, балалар үзләренең туганнарын һәм дусларын бәйрәм белән тәбриклиләр, кизил таягы — Яңа ел символы.

◆ Италиядә Яңа елны Кыш бабай түгел, ә тылсымчы Бефалия алып килә. Имештер, ул төнлә морҗадан өйгә төшә дә балаларга бүләкләр калдыра. Шуңа күрә балалар Бефалияне яраталар. Аны хөрмәтләп урамда бәйрәм ясыйлар. Бефалиянең үзен дә күтәреп чыгалар. Ул кулына факел тоткан кара курчак була.

◆ Советлар Союзында Яңа елны каршылау 9 сәгатькә сузыла: Владивостоктан илебезнең көнбатыш чиге булган Брестка кадәр араны узу өчен Кояшка нәкъ тугыз сәгать вакыт кирәк.

БӘЙРӘМ КИЧЕНДӘ



Яңа елны үз гаиләң белән бергә каршылау нинди күңелле!

Ул көн — ягъни иске елны озату көне, бик мәшәкатьле булса да, шатлыклы, куанычлы була. Табынга гадәттәгедән үз... гә булган яңа ризыклар да куела. Шуны искә алып, печенье пешерү һәм коктейльләр әзерләү тәртибен бирәбез.

...рлек дуслык хакында ... та
...еләр түгел микән әле? Төлке
... курчак уйнаганда беркай-
...каләшмәскә сүз биреште-

...би.
аны
...лим ра...



● 29 декабрь, 1979 ел.

Бәйрәм өстәленә «Яңа ел», «Апельсин», «Алма» коктейльләре ясарга тәкъдим итәбез.

«ЯҢА ЕЛ» КОКТЕЙЛЕ

Ярты стакан кура җиләге суы белән 100 грамм мороженоены ярты стакан сөткә салып болгатыгыз.

«АЛМА» КОКТЕЙЛЕ

Бер стакан алма суы белән ... данә лимон суына бер аш ...ыгы һәм ике шакмак боз ...п, әйбәтләп болгатыгыз.

...Коктейльне ясавы бик җиңел. ...ирәкле әйберләрне бер савытка (шешәгә я термоска) салып әйбәтләп болгатыгыз. Компот җиләкләре, лимон һәм апельсин кисәкләре салсагыз, бу эчемлек тагын да тәмлерәк була.

ЯҢА ЕЛ УЕННАРЫ

ҮЗГӘРЕШ БАРМЫ?

Башта уйнаучылар чыршыны, бер-ике ботагына эленгән уенчыкларны игътибар белән карап торсыннар. Бу уенчыкларның нинди тәртиптә торуын истә калдыру өчен кирәк. Аннары бер кеше бүлмәдән чыгып торган арада калганнары берничә уенчыкның урынын алыштырып куялар я өр-яңа уенчык эләләр. Чыккан кеше бүлмәгә кергәч, ботакларда нинди үзгәреш булганын әйтеп чыга. Иң күп үзгәрешне күрә алган кеше җиңүче дип табыла, һәм аңа бүләк бирелә.

ШАРТЛАВЫК

Шартлавыклар (хлопушка) белән дә күңелле уен оештырып була. Шартлавыкны буй җитәрлек урынга элеп куегыз. Уен башланганда берәрсе шартлавык турысына ук килеп, аны тотып карый. Бу кешенең күзен бәйләп 3—4 адым читкә алып китәләр. Һәм баскан урынында 2-3 тапкыр әйләндерәләр. Шуннан соң ул шартлавык янына килеп, кулларын чәбәкләп, аны шартлатырга тиеш. Моны җиңел генә эшләп булмый. Гадәттә уйнаучы капма-каршы якка китә һәм кулларын чәбәкләп, карап торучыларны көлдереп бетерә.

Газетабызның киләсе саны 1980 елның 5 январенда чыга.

ПФ 05751 КПСС... ...ипографиясендә басылды. Редактор Р. ТУФИТУЛОВА. Зак. 1313.